**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422633,РТ,Лаешрайоны,ТатарСараланыа
вылы, Татарстан урамы, 17 нчейорт,
тел: 8 84378 4-77-49**

**ГЛАВА ТАТАРСКО -
САРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422633,РТ, Лаишевский район, село
ТатарскиеСаралы, ул. Татарстан, д.17
тел: : 8 84378 4-77-49**

2023 елның 01 ноябре 3 номер

# КАРАР

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлегенең Татар Сараланы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлегенең Рус Сараланы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Татар Сараланы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 5500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Рус Сараланы торак пунктында,Үзәк,Центральная, Вишневая, күңелле, Яшьләр, Ягодная урамнары буенча юл-урам челтәрен (ремонтлау, смета буенча юл төзү: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу,салу, контракт буенча эш өчен түләү) норматив хәлгә китерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татар Сараланы авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы
авыл җирлеге Советы рәисе: А.Б. Садыйков**